**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 60**

## I. Гамәли бирем (29 балл)

Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде. Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч, горурлыктан малайның башы күккә тиде. Алар бит икесе дә Салих яшәгән өйдә, дөресрәге, икенче җизнәсе Шиһаб Әхмәров йортында бик еш кунак булалар. Театр, әдәбият-сәнгать турында озаклап гәпләшәләр, уен-көлкеле сүзләр чыктымы, шаулатып көләләр. Ике Габдулла – Кариев белән Тукай – йөзек кашыдай, мәҗлес күрке. Салих һәммәсен игътибар белән тыңларга тырыша. Шушындый мөхтәрәм кунаклар барында үзеңне «зур кеше» шикеллерәк хис итми кара син!

Рашат Низамидан

1. Сүзләрнең синонимнарын языгыз:

белем эстәде, (мәҗлес) күрке, мөхтәрәм, гәпләшәләр, атаклы (**5 балл**)

белем эстәде – белем алды, укыды

(мәҗлес) күрке – мәҗлес яме

мөхтәрәм – хөрмәтле

гәпләшәләр – сөйләшәләр

атаклы – күренекле

2. *Җизни* сүзе нинди туганлык мөнәсәбәтен белдерә? (**2 балл**)

Җизни – үзеңнән зур кыз туганның ире

3. Тексттан биш алмашлык күчереп языгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

**(5 балл)**

ул – зат алмашлыгы

бу – күрсәтү алмашлыгы

алар – зат алмашлыгы

һәммәсе – билгеләү алмашлыгы

үзеңне – билгеләү алмашлыгы

син – зат алмашлыгы һ.б.

4. Затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз, төркемчәләрен билгеләгез.

**(5 балл:** һәр дөрес җавапка 0,5 б.)

тырышып (хәл ф.), укып (хәл ф.), чыгуын (исем ф.), белгәч (хәл ф.), үсеп (хәл ф.), яшәгән (сыйфат ф.), озаклап (хәл ф.), шаулатып (хәл ф.), тыңларга (инфинитив), хис итми (хәл ф.)


5. *башы күккә тию* фразеологизмының мәгънәсен аңлатып языгыз.

**(1 балл)**

бик нык шатлану

6. *Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(5 балл)**

1) *Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде*, 2) *ул бик тырышып шунда белем эстәде.*




Бу - аналитик иярчен урын җөмләле кушма җөмлә.

7. *Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч, горурлыктан малайның башы күккә тиде* җөмләсенең төрен, компонентларның чикләрен, бәйләүче чараны билгеләгез.

**(3 балл)**

1) *Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыгуын белгәч,* 2) *горурлыктан малайның башы күккә тиде.*
Бәйләүче чара -гәч хәл фигыль кушымчасы.

*Бу* – синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә.

8. Сүзләргә морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**

*Гәпләшәләр, кашыдай, уен-көлке*

*гәпләшәләр* – хикәя фигыль, затланышлы, барлыкта, хәзерге заманда, III зат күплек санда, ясалма сүз.

*кашыдай* – охшату-чагыштыру рәвеше, ясалма сүз.

*уен-көлке* – уртаклык исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, парлы сүз.

## II. Теоретик бирем. (6 балл)

Җөмләнең баш кисәкләре турында, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерлүләрен аңлатыр языгыз. Өч гади җөмлә мисалында аңлатыгыз.

Ия белән хәбәр җөмләнең баш кисәкләре дип атала. Баш кисәкләр җөмләнең грамматик нигезен барлыкка китерә. Башка сүзләргә буйсынмый торган баш кисәк ия дип атала. Хәбәр – ия турында хәбәр итә, аңа ияреп килә торган баш кисәк.

Ия дә, хәбәр дә төрле сүз төркемнәре (исем, алмашлык, сыйфат, сан, рәвеш, фигыль) белән белдерелә ала. Фигыльдән башка сүз төркеме (исем, алмашлык, сыйфат, сан, рәвеш) белән белдерелгән хәбәр исем хәбәр дип атала.

ис. ис.
Акбай – безнең яраткан эт.

алм. фиг.
Мин аны ашатам.

сыйф. ис.
Соры – матур төс.

## III. Иҗади бирем. (25 балл)

Тукай терелгән, ди. Һәм сезгә аның белән очрашу мөмкинлеге бирелгән икән. Шул кыска гына вакыт эчендә бөек шагыйребезгә нәрсә турында сөйләр, аңарга нинди сораулар бирер идең?

“Тукай белән очрашу” темасына 20-25 җөмләдән торган текст төзеп языгыз.